РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«09» 01 2018г. №1

2018 елда Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы гомуми
белем бирү учреждениеләрендә
укучыларныц туклануын оештыру турында

2012 елның 29 декабреннән булган “Россия Федерациясендә белем бирү турында”гы 273 санлы Федераль Законга, 2017 елның 8 сентябреннән булган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2018 елга ай саен түләнелә торган акчалата һәм башка түләүләр турында”гы 641 санлы Карарына ярашлы һәм Ютазы муниципаль районы мәгариф учреждениеләрендә укучыларның азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм туклануларын оештыру максатында, Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар итә:

1.2018 елның 1 гыйнварыннан түбәндәгеләрне расларга:

Урыссу ш.т.б. белем бирү учреждениеләрендә туклану бәясен көнгә 42 сум 10 тиен күләмендә булачак, шул исәптән:

- бер укучыга уку чорында көнгә 7 сум 10 тиен күләмендә субсидия,
- уку чорында бер укучыга көнгә 35 сум 00 тиен күләмендә эти-әниләр түләүләре взнослары карала;
- авыл гомуми белем бирү учреждениеләрендә бер укучыга туклану бәясен көнгә 39 сум 10 тиен күләмендә расларга, шул исәптән:
- уку чорында бер укучыга көнгә 7 сум 10 тиен күләмендә субсидия билгеләргә;
- уку чорында бер укучыга 32 сум 00 тиен күләмендә эти-әниләр түләве билгеләргә.

2.Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениедәрендә социаль якланмаган гаиләләрдән укучыларның туклануын оештыру тәртибе турында Нигезләмәне (Кушымта) расларга.

3.Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы финанс-бюджет палатасына Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль

районы бюджетында әлеге максатларга 2018 елга “Мәгариф” тармагы буенча каралган чаралар чигендә муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларга туклануга чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2018 елның 1 гыйнвардан булган хокукый мөнәсәбәтләргә тарала.
5.Әлеге Карарныц үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль сораулар буенча урынбасарына йөкләргә.
ТР Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина.

Җитәкче С.П. Самонина